# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **24.11.2023 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенә керүче Югары Стәрле авылында 2024 елда үзара салым жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегендә халык җыены карар бирә:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Югары Стәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 (биш йөз) сум күләмендә, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасы тупланган гаиләләр, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2 группа инвалидлар өчен 250 сум күләмендә түләүне киметергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:

- Югары Стәрледә юлларны тигезләү ( килешү буенча түләү);
- Югары Стәрледә юлларны кардан чистарту ( килешү буенча түләү);
- Югары Стәрле авылы урамнарны яктырту (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);
- Югары Стәрле авылында халык күпләп ял итә торган урын “Сабантуй” мэйданын төзекләндерү( сэхнэ, беседка, капка, бизэу тасмалары сатып алу, торба баганалар сатып алу һәм урнаштыру) һәм мэйдан яннарын төзекләндерүне оештыру(чүп үләннәреннән чистарту хезмәтләре күрсәтү);
- Балалар мэйданчыгы сатып алу;
- Югары Стәрле авылы “Мирас” парк территориясен төзекләндерүне оештыру (территорияләрне чүп үләннәреннән чистарту, агачлар һәм куаклар, чәчәкләр утырту (килешү буенча түләү);
- Беренчел пожар куркынычсызлыгы буенча чаралар ( ДЕПО корылмасына ремонт эшлэре: тозелеш материаллары сатып алу хэм тозеклэндеру хезмэте курсэту (килешу буенча тулэу); турындагы карар кабул ителде.

3. Әлеге халык жыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Югары Стәрле авылы, Совет., 32г йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,

Югары Стәрле авыл җирлеге башлыгы: Сабиржанова Л.С.